ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2019 г. Заинск № 58

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 6 мартындагы 360 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында”**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2018 елның 4 июнендәге 146-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 6 мартындагы 360 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында " карарына (2018 елның 18 июлендәге 1186 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә;

1.9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә административ регламентлар Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый акты яки җирле үзидарәнең башка органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә раслана.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

А.Н. Симашева
3 41 33